Марсель Галиев

Шүрәле һәм Җил

Марсель Галиев

Шүрәле һәм Җил

ШИГЫРЬЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1990

ББК 84 (2Р-Тат)-5
Г 18

Художнигы *В. Булатов*

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРГА

Г $\frac{4803560202-102}{М\ 132(03)-90}$ 195—90

ISBN 5—298—00494—6

© Марсель Галиев, 1990

© В. Булатов, рәсемнәр, 1990



ТАНЫШУ НИДӘН БАШЛАНА?

Ни генә юк бу чормада:
Иске урак дисеңме,
Чабагачлар, шүре, киле —
Бар да серле исемле.

Бабайлардан калган әйбер
Почмакларга өелгән.
Тузаннарын кагып алам —
Танышам мин өй белән.

Ни генә юк авылымда:
Тәмле чишмә сулары,
Кәҗә сукмагыннан менсәң,
Җил сызгырта таулары.

Каен урманына кадәр
Күпме өйләр тезелгән.
Санап чыгам морҗаларын —
Танышам авыл белән.

Бормалы юллардан китеп,
Ил буйлап йөрсәң иде,
Диңгез, таулар һәм тайгалар,
Шәһәрләр күрсәң иде.

Серләр челтәреннән торган
Картага мин иеләм,
Үсеп җиткәч, дөнья гизеп,
Танышырмын ил белән.



ИРТӘНГЕ КОЯШ

Мин көтүгә чыккач күрдем
Кояшның уянганын.
Кем уята микән иртән,
Әнисе юк бит аның?

Киерелеп торды кояш,
Ачып болыт юрганын.
Үзем күрдем,
Чык-су алып
Аның битен юганын.

Таңгы кояш күзне чакмый,
Карап була кояшка.
Әнә нәзек нурлар сузды
Мин басып торган ташка.

Манып алды кызгылт нурга
Ябалдашын талларның.
Күз алдында биегәйде
Түбәләре тауларның.

Яңа уянган кояшның
Йөзе дә бит сипкелле...

Агачлардан чыклы җиргә
Күләгәләр сикерде,
Шүрәлеләр шикелле!

ДИҢГЕЗ ТАШЛАРЫ

Диңгез ташлары апкайтты
Әти миңа көньяктан.
Мең еллар буена алар
Диңгез төбендә яткан.
Ярга кагып ул ташларны
Дулкын шулай шомарткан,
Дип аңлатты әти миңа,
Ул үзе күреп кайткан.

Яшел, кызыл, ак ташларны
Берәмләп алам кулга.
Төрле төстә балкып китә
Салып карагач суга.
Кипкәч тагын сүнеп кала,
Керә тонык төсләргә.
Сусыз калган балык сыман
Ята алар өстәлдә.

Сусыз аларга кыендыр,
Сүнмиләрдер тикмәгә.
Мин ташларны кызгандым да
Илтеп салдым чишмәгә.

ҖИЛКУАР МАЛАЙ

Әни миңа өй җыярга
Кушып киткән иде дә...
Ә мин йөрдем трай тибеп
Көне буе биләмдә.

Кайтып керсәм... бик ашыгып,
Өйдә сәер тамаша.
Үзара бар әйберләр дә
Тын гына пышылдаша.

Күзгә кинәт мине күргәч,
Арты белән борылды.
Өстән генә карап чөйде
Суык чәйнек борынын.

Ә өстәлнең бер почмагы
Авырттырып кагылды.
Кем куйган аяк астына —
Буш чиләккә абындым.

Чиләк зеңли-зеңли китеп,
Әй, зарлана башлады.
Бәллүр ваза каш астыннан
Шундый караш ташлады!..

Җитмәсә бу роза гөле
Кулны чәнчеп ала бит!
Келәм, бөгәрләнеп килеп,
Аяк чалган була бит...

Бар да миңа үпкәләгән,
Бар да мине ят итә.
Песи булсаң иде хәзер!
Әнә ничек,
Берни белми, ял итә...

ГЕР ЧӨЮЧЕЛӘР

Хәким абыйның беләге
Тимер кебек зыңлап тора.
— Көчле син! — дип мактасалар,
Тыйнак кына тыңлап тора.
Бер кузгалса, туктар димә!
Ничек армый, ничек туймый?
Ике потлы герләрне ул
Капка аша чөеп уйный.

Аннан хәтәррәк булган
Әтисе дә көч ягыннан.
Бер эскертне каерып алса,
Сыйдырган ул кочагына.
Герне балдак сыман гына
Чәнти бармагына киеп,
Ала икән, ата икән
Өй түбәсе аша чөеп.

Утыргычта Зәки бабай
Моны безгә сөйли шулай:
— Бабалары да аларның
Өяздә бер! Дан тоткан, — ди, —
Тик бервакыт артык көчле
Икәнлеген оныткан, — ди, —
Алагаем селтәнгән дә
Күккә таба чөйгән герне.
Югалган гер, шуннан бирле
Төшалмаган җиргә кире.

Ышанмыйсыз инде әллә?..
Кара әнә, гер тигәнме?!
Җиз коштабак кебек Айның
Бер кырые яньчелгәнме?
Шулай шул!..

ХӘТЕР

Кара мундирлы фашистлар
Бәйгә алып этләрен,
Чылбырдай тезелеп килә.
Алда ниләр көткәнен
Белми әле, белми алар...
Мин пулемет артында
Көтеп ятам, тешне кысып,
Килсен алар якынга!

Йөзләрен ап-ачык күрәм,
Сызганулы җиңнәре.
Артта дөрләп яна күкләр —
Канлы офык иңнәре.

Менә хәзер, менә хәзер
Сыныйм пулемет көчен!
Кинәт кулны тешләп алам
Калтырамасын өчен...

Калды мизгел!
Кирәк миңа
Шундый түзем, чыдамлык...

Төш булып уята мине
Бабай күргән чынбарлык...

УЯНДЫ АЛАН

Җиләкләр карый кызарып
Кәрешкә арасыннан.
Кыңгырау чәчәк тажына
Күбәләк канатыннан
Алтынсу тузан коелды —
Җемелди, күр әле син!
Уйнаклап оча күбәләк —
Җилферди күләгәсе.

Башлаган җырын онытып,
Сокланып үз-үзенә,
Көяз чикерткә төбәлгән
Чык тамчысы — көзгегә.
Ат пошкырган якка карап
Кузгалды кигәвен дә.
Черки чарлады борынын,
Тешләр кемне бүген дә...

Бүрәнә итеп чыбыкны
Җилкәләренә салып,
Йөз кырмыска кайтып килә
Бер сулышка тын алып.
Ә бал корты тәпиләрен
Ник ышкый бер-берсенә?
Тезләренә кадәр баткан
Ак чәчәк серкәсенә.

Мең чәчәк һәм мең бөҗәкле
Дөнья уянган күптән.
Ә нигә соң, ә нигә соң
Чиләкле апалар бүтән
Алан эзләп кузгалган?
Яфрак астына йомылып,
Җиләкләр качкан булган!..

АҚ ҚҮЛМӘКЛЕ МАЛАЙ УЕ

Нәни генә туп йоткандыр —
Бака шуңа сикерә.
Ник сикерми җирдә генә,
Күл суына ник керә?

Сырты кара җир төсендә,
Ә түше ап-ак аның.
Гел юынып тору кирәк —
Серен белдем баканың!



ҖӘЙ ХОЗУРЫНДА

Җыр суза тавыклар кетәктә,
Чыпчыклар коена тузанда.
Пырхылдап очалар куакка
Урамнан машина узганда.

Кәҗәләр бүрәнә каезлый —
Усакның тәмледер кайрысы.
Бакчадан күзләрен алмыйча
Коймага ышкына кайсысы.

Аръякта, мылтыктан аткандай,
Көтүче чыбыркы шартлата.
Песинең колагын селкетеп
Яңгырый кайтаваз: та-та-та...

Иң соңгы авазлар тынуга,
Таллыклар артында сөзелеп,
Кошларга җан керә яңадан —
Ялгана калган җыр өзелеп.

Күкенең тавышы үзгәргән,
Сакаулый, салкынмы тигәндер?
Ә бәлки, үз моңын үзгәртеп,
Сандугач буласы килгәндер.

Саескан куна да түбәгә,
Тимерне тимергә бәргәндәй,
Чикаклый туктаусыз бер көйгә
Ниндидер кисәтү биргәндәй.

Саескан кундымы, өлкәннәр
Кунаклар кайтуын көтәләр.
Ак оннар тугыла коймакка,
Җиләкле какларын сүтәләр.
Мин әле нишләп соң утырам
Берни дә белмәгән туп тотып.
Әнинең:
— Онытма, су апкайт! —
Дигәнен бөтенләй онытып...

ЯЗГЫ МИЗГЕЛ

Тилгән тора күккә кадакланып,
Чирәмлектә нәни бәбкәләр.
Башын кыңгыр салып, ата казлар,
Ысылдашып, күккә дәшәләр.

Тилгән һаман җепкә асылгандай —
Канат очларын да селкетми.
Сиздермичә җиргә якыная,
Ысылдауга аның ис китми.

Каз саклаган бабай йоклап киткән,
Тез аркылы салып таягын.
Нәкъ вакытлы уяттылар аны
Ике бәбкә, чукып аягын...

БЕЗ — ДҮРТӘҮ.

Иң алдан гел туп йөгерә,
Аның артыннан — Муйнак.
Алардан соң мин йөгерәм,
Арттан җил килә уйнап.

Йөгерәбез дүртәүләшеп,
Хәйләкәр туп гел алда.
Әни өйгә чакырмаса,
Уйга килми туктау да.

Кайткан чакта иң алда — җил,
Муйнак узалмый җилне.
Ә туп миннән күтәрттергән,
Ул уйнап арган инде...

ШҮРӘЛЕ ҺӘМ ҖИЛ

Ялкау гына искән Җилне
Тотып алган Шүрәле.
Җилнең моңарчы булмаган
Мондый җанвар күргәне.

Башта каушап калган, ди, Җил,
Дер-дер килеп, калтырап.
Йомшак дәшкән Шүрәлегә
Карап торган аптырап.

Алай усал түгел икән
Ялгыз урман сарыгы.
Кети-кети уйнарга дип,
Иптәш көткән зарыгып.

Рәхәт булып киткән Җилгә
Шомлы урман куены.
Ризалашкан, бик ошатып,
Шүрәленең уенын.

Ә Шүрәле ипләп кенә
Кытыкларга тотынган.
Тамашаны карар өчен
Кошлар, агачлар тынган.

Җилнең көлү капчыклары
Берәм-берәм чишелгән.
Шарлавыктай аккан көлү —
Гүя күкләр ишелгән.

Әй, көлә Җил, әй, көлә, ди,
Сикергәли, әйләнә.
Тик бераздан аңлап алган
Капканын бу хәйләгә...

Шүрәленең бармаклары
Қыза гына бара, ди.
Җилнең инде көлә торгач,
Эчен кату ала, ди.

Кинәт...
Елауга күчеп Җил
Бөтерелә башлаган.
Ярсып, бөтен тирә-юньне
Актарып та ташлаган.

Шүрәлене койрыгыннан
Агачларга ураган.
Хәтәр көчле давыл булып
Күтәрелгән урманнан.

Ачуыннан дер селкетеп
Урап йөргән дөньяны.
Бүтән бер дә көлмәскә дип,
Сүз биргән диләр аны.

Аннан тәмам хәлдән таеп
Төшкән упкын төбенә
Кырык төн һәм кырык көннән
Чыккан дөнья йөзенә.
Ул инде нәкъ элеккечә —
Давыл түгел, Җил генә.

Шуннан бирле исми, ди, Җил,
Урман эченә кереп,
Агач башларыннан гына,
Уза икән җилдереп...

БӘХЕТЛЕ БУЛУ НИЧЕКТЕР

Әти белән икәү бергә
Йөри идек урманда,
Таптым пошп мөгезе мин
Түм-түгәрәк аланда.

Пошп мөгезе тапканнар
Бик бәхетле була, дип,
Әти мине сөеп куйды,
Игътибарлы бала, дип.

Ун тармаклы каты мөгез
Шүрәле кулы сыман.
Җил ертылмый үтә алмас
Бармаклар арасыннан.

Мөгезне мин иңгә салдым.
Горурмы килеш-килбәт?!
Бәхетле булу ничектер,
Миңа болай да әйбәт...

ТӨСЛЕ ЯҢГЫР

Яшел яңгыр, яшел яңгыр
Таллыклар ешкынында.
Кызыл яңгыр, кызыл яңгыр
Комлы тау ышыгында.

Зәңгәр яңгыр, зәңгәр яңгыр
Инеш дулкыннарында.
Сары яңгыр, сары яңгыр
Якты бодай кырында.

Болыт җиргә җепләр сузып
Төсләрдән чигү чигә.
Бизәкле келәм әзерли
Бүләккә игенчегә.

ОЯЛУ

Үрә басып Муйнак өрә,
Тимер чылбыр шау тартылган.
Кабарынган Мырауҗанны
Өзгәләп тә атар сыман.

Пәрәвез җебе сыярлык
Ике борын арасында:
Шундый якын килеп баскан
Песинең карашында

Бер курку юк, беләдер шул
Чылбырының озынлыгын,
Муйнак күпме тартылса да,
Үтәлми шул чик сызыгын.

Күзләр — күздә. Сынашалар,
Кайнар сулыш бөрки-бөрки.
Өндәү кебек койрыклары
Сөйләшәләр үрти-үрти.

— Исем китте өрүеңә,
Мин юлбарыс нәселеннән.
Безнең кавем өстен тора
Сөяк ялау кәсебеннән.

— Син бер эшсез мич башында
Үткәрәсең йоклап кына.
Төн вә көндез минем кебек
Ихатаны саклап кара!

— Сөйләнәме, һи-и, сиңамы,
Бүре килсә, чыгасыңмы?
Койрык чәнчеп тынасыңмы!
— Юлбарыс бабаң ишетсә
Тычкан аулап йөргәнеңне,
Бирер иде кирәгеңне!

— Син үзең кем?! — Алак-шалак!
— Кит яшел күз!!
— Салпы колак!..

Кинәт алар тынып калды,
Шомырайды колаклары.
Ике арада — чик сызыгы,
Тибри үлән сабаклары.

Карасалар... бер кырмыска
Кайтып килә тирләп-пешеп.
Иңендә йөк — үзеннән зур,
Бу, ичмасам, — ирләр эше!

Мырауҗанның күз кысылды,
Яшел уты сүнеп куйды.
Телен чыгарды да Муйнак,
Юашланып, чүгеп куйды.

Кырмыскага юл саптылар,
Ачу-бәхәс төгәлләнде.
Оялудан, өтер булып,
Койрыклары бөгәрләнде.



ҮЧ АЛДЫ БУГАЙ

Сугыша белмим, малай,
Күп-күмгәк булды маңгай...

Шундый каты бер йодрык
Килеп төште маңгайга.
Күздән утлар күренсә дә,
Кабынмадым алай да.

Тәгәри киткән йодрыкны
Тотып алдым тиз генә.
Ай-һай каты алма икән,
Тешләрем төзсен генә!

Хәтерләдем, теге чакта
Алма төбен утарга
Әни кушкач, тыңламыйча
Чыгып киттем уйнарга.

Әйткәндер шунда алмагач:
— Өйрәтәм бу малайны!
Ә мин хәзер ничек каплыйм
Шешеп чыккан маңгайны?

Әни сорамый калмас,
Сугыштым дими булмас...

ТАМАША

Әтәч койрыклы кәҗә
Сакалын җирдән сөйри.
Сакалына басмыйм дип,
Артка чигенеп йөри.

Алты мөгезле сыер
Аклы-каралы туннан.
Һәр мөгезнең иң очына
Берәр сыерчык кунган.

Кара күзлекле Муйнак
Китап тоткан, күр әнә!
Мәчене куркытмаска
Өрү фәнен өйрәнә.

Өч аяклы ата каз,
Бүреген кыңгыр салып,
Чәлдер-чөлдер күркәне
Күзәтә хәйран калып.

Җилпәзә җәйгән күркә
Сикертә кашсыз кашын.
Кай ара сарык белән
Алышкан нәни башын.

Сары томшыклы чеби
Тилгәнгә куйган капкын.
Сыңар канатлы тилгән
Капкынга килеп капкан.

Өй кыегында кояш
Авыз кыйшайтып көлә.
Кармак тотып түбәгә
Сак мәче менеп килә.

Бу ни тамаша диеп,
Кызыксынсаң син әгәр,
Минем рәссам энекәш,
Була дип шундый хәлләр,
Альбомын ачып ташлар,
Мин шулай күрәм диеп,
Кызып аңлата башлар.

ҚЕСӘЛЕ

Әни миңа чалбар алды,
Ҡесәле шул кесәле!
Бер җәйдә бер карышка
Ҡинәт кенә үс әле,
Ничек алмасын ди чалбар,
Ҡесәле шул кесәле.
Искесе бик кыска калган,
Ул бит инде кичәге...

Бар да сыя чалбарыма —
Ике тирән кесәле.
Анда компас, анда пәке,
Анда ипи кисәге.

Менә нинди минем чалбар,
Ҡесәле шул кесәле.
Ипи сиңа, Муйнак, аша,
Әйдә син дә үс әле!

АК РӘСЕМ

Буранның ак койрыгы
Бәкедә туңып калган.
Тәрәзәдә — җәй хәтере,
Боз арышлар ясалган.

Нинди рәхәт, нинди тыныч,
Туя алмассың уйнап.
Көрткә чума-чума ауный
Өтер койрыклы Муйнак.

Моржалардан кайнап-кайнап
Зәңгәр төтен үрелә.
Ак тын бөркеп сыер мөгри
Ишегалды түрендә.

Алма-алма кызылтүшләр
Куактан сибелешә.
Кар борынлы булган Муйнак —
Аңа бик тә килешә.

Муйнак нигә өреп куйды,
Ник курыкты кинәттән?
Мөгезенә иләк элеп,
Кәҗә чыккан келәттән!

Кем сызгырды җил чакырып?
Карлар төшә бик акрын,
Исәбе юк тузгырга.
Буранның бит ак койрыгы
Ябышып калган бозга.

ҖӘЯҮЛЕ БУРАН

Әй, йөри җәяүле буран
Шәһәрем урамында.
Адашыпмы, ялгышыпмы
Килеп чыккан ул монда.

Кызыл утка килеп керде,
Ак койрыгын сөйрәп.
Таптала бит! Таптала бит,
Ничек коткармак кирәк.

Трамвайның астыннан ук
Ярый чыгып өлгерде.
Койрыгын сыртка салды да
Алга таба йөгерде.

Әче итеп сызгыргалап,
Афишалар умырып,
Йөри ул анархист сыман,
Урамны пыр туздырып.

Куян бүрек, төлке бүрек,
Кемнәр бүре бүректән;
Йолкып алып атты буран,
Кызыгып йөргән күптән.

Шулай очынып алды да,
Машиналарны узып,
Шәһәремнән чыгып китте
Ак койрыгын сузып.

Кайтып китте кузгатырга
Усал бүре өннәрен.
Ә сыртында... күреп калдым:
Чана, тояк эзләре.

ЭЧТӘЛЕК

Танышу нидән башлана	3
Иртәнге кояш	4
Диңгез ташлары	5
Җилкуар малай	6
Гер чөючеләр	7
Хәтер	8
Уянды алан	9
Ак күлмәкле малай уе	10
Җәй хозурында	11
Язгы мизгел	13
Без — дүртәү	14
Шүрәле һәм җил	15
Бәхетле булу ничектер	18
Төсле яңгыр	19
Оялу	19
Үч алды бугай	22
Тамаша	23
Кесәле	25
Ак рәсем	26
Җәяүле буран	27

Галиев Марсель Баянович

ШУРАЛЕ И ВЕТЕР

Стихи

(на татарском языке)

Редакторы *М. Фәйзуллина*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Р. Ильясова*
Корректоры *С. Мифтахова*

ИБ № 5714

Жыярга тапшырылды 07.02.90. Басарга кул куелды 27.03.90. Форматы $70\times90^{1}/_{16}$. Офсет. кәгазе № 1, 100 гр. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 2,05. Шартлы буяу-оттиск 9,37. Нәшер-хисап табагы 2,35. Тиражы 50 000 экз. Заказ № Д-62. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

20 тиен.